Республика Татарстан
Глава
Какре-Елгинского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Кәкре Елга авыл җирлеге
башлыгы

ул. Советская, д. 22, село Какре-Елга,
Азнакаевский район, 423320

Совет урамы, 22 нче йорт, Кәкре Елга авылы,
Азнакай районы, 423320

Тел. (факс) 8(85592) 37-0-47; e-mail: Kelg.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «31» октябрь 2022ел . № 3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Кәкре Елга торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Уставы белән,

**КАРАР** чыгарам:

1. 2022 елның 11 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга Кәкре Елга авыл җирлегендә 2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җыенның беренче этабын Кәкре Елга авылында Совет урамының 1нче йортыннан 73нче һәм Сәпәй 1нче йортыннан 33нче номерлы йортларына Кәкре Елга авылында теркәлгән гражданнар өчен билгеләргә.

2. 2022 елның 11 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлегендә 2023 елда гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җыелышның икенче этабын Кәкре Елга авылында Профсоюз урамының 1 нче йортыннан 40 нчы йортка кадәр, Яшьләр урамының 1 нче йортыннан 21 нче йортка кадәр, Кәкре Елга авылында теркәлгән гражданнар өчен билгеләргә.сайлау хокукына ия булган Мэктэп урамынын 1нче йорттан 29нчы номерлы йортларына Кәкре Елга авылында теркәлгән гражданнар өчен билгеләргә.

3. 2022 елның 11 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга Кәкре Елга авыл җирлегендә 2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын Кәкре Елга авылында Комсомол

урамының 1нче йортыннан 51нче йортка кадәр, Заречная урамының 1нче номерлы йортларына Кәкре Елга авылында теркәлгән гражданнар өчен билгеләргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган тубэндэге мәсьәләләрне расларга:

"2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме, моңа 1 нче группа инвалидлары, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, өлешчә мобилизацияләүгә юнәлдерелгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларын керми , бер тапкыр түләүне киметеп аны 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә билгеләргә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

-Кәкре Елга торак пунктында «Сабантуй» уздыру урынын төзекләндерү (материаллар сатып алу, контракт буенча эшләр башкару) ;

-Кәкре Елга торак пунктында халыкны су белән тәэмин итүне, суларны агызуны оештыру (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, контракт буенча эшләр өчен түләү, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру, эчәргә яраклы суга биохимик һәм бактериологик анализ үткәрү) ;

- Күмү урыннарын карап тоту (ТКО бункерларын сатып алу, бункерлар өчен мәйданчык һәм аларга керү юлын ясау);

- механикалаштырылган кар чистарту буенча тракторчы хезмәтләре өчен түләү, Кәкре Елга торак пунктындагы юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре;

-Кәкре Елга торак пунктында бәйрәм чараларын оештыру һәм уздыру («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») ;

- спорт чараларын оештыру һәм уздыру ( бүләк алу) ;

- Кәкре Елга торак пунктында спорт мәйданчыгы өчен тренажерлар сатып алу һәм урнаштыру;

-Кәкре Елга торак пунктында чишмәләр территориясен төзекләндерү (чишмәне каптажлау өчен материаллар сатып алу) ;

- Кәкре Елга торак пунктында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары (килешү буенча хезмәт хакы, тракторлы техниканы арендалау, запас частьләр сатып алу һәм ягулык-майлау материаллары) ;

-җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияне механикалаштырылган чабу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу) - Кәкре Елга торак пунктында;

« ЭЙЕ» «КАРШЫ».

Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. Һәм 22 йорт Совет урамы Кәкре Елга

авылы   Азнакай муниципаль районы РТ  адресы буенча урнашкан  авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга
5. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык И.М.Мөхәмәтҗанов